# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге составына керүче Күки торак пунктында.

21 ноябрь, 2025 ел

№ 1

2025 нче елның 20 мартындагы Федераль законның 45,69 статьялары нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2025 ел, № 33 - ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлегенең Күки торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлегегендәге көндезге формада укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Президенты В. В. Путин игълан иткән махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан, шулай ук аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл ититүгә юнәлтеп.

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
2. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
4. Торак пунктларның башка территорияләрен төзекләндерү;
5. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов